КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.06.2023 Казан шәһәре № 218-П

Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Мәчти т.п. адресы буенча урнашкан «Мәчти некрополе» мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы карары һәм мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны карау акты нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Мәчти т.п. адресы буенча урнашкан «Мәчти некрополе» мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә.
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н. Гущин